ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарын рәсми аңлату турында гражданка М.Н. Павлова үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында**

Казан шәһәре 2017 елның 26 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка М.Н. Павлова мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка М.Н. Павлова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2006 елның 8 ноябрендәге 2346 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәре территориясендә гражданнарга торак биналарны хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) барышында документлар рәсмиләштерү тәртибе турында» инструкциягә 2 нче кушымтадагы алтынчы абзацның һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 28 июнендәге 4310 номерлы карары белән расланган Торак биналарны гражданнарга хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) килешүләрен рәсмиләштерү буенча муниципаль

хезмәт күрсәтүнең административ регламентының II бүлегендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы уникенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарын рәсми аңлату турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карары белән дәгъва белдерелә торган нормалар теркәүдән балигъ булмаган гаилә әгъзалары төшерелгән торак урынны хосусыйлаштыруга гаризаны рәсмиләштерү өчен опека һәм попечительлек органнарының рөхсәте булу кирәклеге турындагы таләпне билгеләү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дип танылдылар.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, хокук куллану органнары, карала торган нормаларны ялгыш шәрехләп, опека һәм попечительлек органнарының рөхсәтен торак урыннан теркәүдән төшкән балигъ булмаган затларның яллаучының гаилә әгъзалары булу-булмауларына карамастан тапшыруны таләп итәләр. Шул ук вакытта гражданка М.Н. Павлова фикеренчә, күрсәтелгән рөхсәтне тапшыру турында дәгъвалана торган нормалар белән билгеләнгән таләп бары тик гариза бирүче вәкаләтле органга хосусыйлаштыруны рәсмиләштерү өчен мөрәҗәгать итү моментына яллаучының гаилә әгъзалары булган торак урыннан теркәүдән төшкән балигъ булмаганнарга гына кагыла. Шунда ук ул ассызыклаганча, Россия Федерациясе Торак кодексының 69 статьясындагы 1 өлеше нигезендә яллаучының гаилә әгъзалары булып аның белән бергә яшәүче ире (хатыны), шулай ук әлеге яллаучының балалары һәм ата-анасы, шулай ук башка туганнары, әгәр алар яллаучы тарафыннан йортка аның гаилә әгъзалары буларак кертелгән булсалар һәм аның белән уртак хуҗалык алып барсалар, саналалар.

Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарын аңлатуны, атап әйткәндә,

дәгъвалана торган нормалар Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип шул исәптән опека һәм попечительлек органнарының рөхсәтен тапшыру турында билгеләнгән таләп торак урыннан теркәүдән төшкән балигъ булмаганнар яллаучының гаилә әгъзалары булмаган очракларга кагылмаганга күрә танылганмы дигән сорауга җавап бирүне сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма, аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия затның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы һәм 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип шулай ук күрсәткән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы билгеләмәләр).

Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарының дәлилләү өлеше эчтәлегеннән аңлашылганча, дәгъвалана торган нормаларны системалы шәрехләүдән чыгып, балигъ булмаган зат теркәүдән төшерелгән торак урынны хосусыйлаштыруга опека һәм попечительлек органнарының рөхсәте торак урынны хосусыйлаштыру элегрәк аннан теркәүдән төшерелгән, ләкин аннан

файдалану хокукын югалтмаган балигъ булмаган зат катнашуыннан тыш башкарылса гына, шул исәптән хосусыйлаштырыла торган торак урыннан теркәүдән төшерелгән, ләкин әлеге торак урыннан файдалану хокукын югалтмаган балигъ булмаган затның законлы вәкиле балигъ булмаган затның хосусыйлаштыруга хокукын гамәлгә ашырудан баш тарткан очракта таләп ителергә мөмкин.

Күрсәтелгән нормаларны караганда, Татарстан Республикасы Конституция суды аларны гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыннарыннан, шулай ук сүзгә-сүз эчтәлекләреннән һәм дәгъвалана торган нормаларның көче тарала торган балигъ булмаганнарның чикләнгән даирәсен күздә тота торган хокукый мәгънәсеннән чыгып, шул исәптән әлеге җайга салуның яллаучының гаилә әгъзалары булган теркәүдән төшерелгән балигъ булмаганнар мөнәсәбәтендә кулланылуын исәпкә алып бәяләгән.

Яллаучының гаилә әгъзасы булып кем саналу мәсьәләсе Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан махсус тикшерелмәде, чөнки ул мөрәҗәгать итү предметын тәшкил итмәгән иде. Шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан тиешле аңлатмалар бирү ачыктан-ачык 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарының эчтәлеге чикләреннән чыгар иде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карары өстәмә тәфсилләүне яисә аныклауны таләп итми, чөнки аның эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нормаларына тулысынча таяна һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк.

Мөрәҗәгать итүченең оныгы Россия Федерациясе Торак кодексының 69 статьясы нигезләмәләре кысаларында аның гаилә әгъзасы булып саналамы-юкмы турындагы мәсьәләгә килгәндә, ул Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил итмәгән иде һәм тәшкил итә алмас иде дә. Һәр конкрет очракта әлеге мәсьәләне ачыклау факттагы

шартларны билгеләүне, тикшерүне һәм бәяләүне күздә тота һәм бары тик вәкаләтле хокук куллану органнары тарафыннан башкарыла, соңгылары, үз чиратында, карала торган норматив нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 һәм 59 статьялары белән билгеләнгән төп хокукый принципларны боза торган киңәйтеп аңлатуның рөхсәт ителмәве турындагы Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позициясен игътибарсыз калдырмаска тиеш.

Гражданка М.Н. Павлова үтенечнамәсеннән шулай ук аңлашылганча, аның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгате, асылда, 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарда булдырылган хокукый позицияләрдә билгелелек яки ачыклык булу-булмауга түгел, ә хокук куллану карарларында дәгъвалана торган нормаларны интерпретацияләүгә бәйле. Ләкин шундый карарларның законлы һәм нигезле булу-булмавын тикшерү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2006 елның 8 ноябрендәге 2346 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәре территориясендә гражданнарга торак биналарны хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) барышында документлар рәсмиләштерү тәртибе турында» инструкциягә 2 нче

кушымтадагы алтынчы абзацның һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 28 июнендәге 4310 номерлы карары белән расланган Торак биналарны гражданнарга хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) килешүләрен рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының II бүлегендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы уникенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 21 октябрендәге 70-П номерлы карарын рәсми аңлату турында гражданка М.Н. Павлова үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү өчен әлеге карарны рәсми аңлату таләп ителми.

2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка М.Н. Павловага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 1-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**